КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 сентябрь г.Казань № 863

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карары белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә, аны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

бу карар редакциясендәге Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенең 2.1 нче пунктындагы өченче абзацының көче 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип;

бу карар редакциясендәге Тәртипнең 3.6 нчы пунктындагы дүртенче абзацының көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин